КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 25 июнь г.Казань № 513

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән расланган Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 8 апрель, 205 нче; 2018 ел, 13 декабрь, 1128 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Дәүләт йөкләмәләре һәм дәүләт йөкләмәләрен үтәү турында хисаплар, алар үз эченә алган дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлардан тыш, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты тарафыннан

билгеләнгән тәртиптә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру буенча рәсми сайтта (www.bus.gov.ru) урнаштырыла, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге карамагында казна учреждениесе булган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләрнең һәм дәүләт бюджет учреждениесен яки автоном учреждениене гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы органнарның рәсми сайтларында урнаштырыла ала.

Карамагында казна учреждениеләре булган Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр һәм дәүләт бюджет яисә автоном учреждениеләрне гамәлгә куючыларның функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы органнар үз карамагындагы учреждениеләргә дәүләт (муниципаль) биремнәрен урнаштыруны тәэмин итәләр, әлеге мәгълүматны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне планлаштыруның һәм мониторинглауның бердәм ведомствоара системасы аша биреп.»;

әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада:

1 өлешнең 3 пунктындагы 3.2 пунктча таблицасының «Дәүләт хезмәте күрсәтүнең билгеләнгән сыйфат күрсәткечләреннән рөхсәт ителгән (мөмкин) тайпылышлар» графасының исемендә «сыйфат» сүзен «күләм» сүзенә алмаштырырга;

2 өлешнең 3 пунктындагы 3.2 пунктча таблицасында:

«Эш сыйфаты күрсәткечләренең мәгънәсе» графасының исемендә «сыйфат» сүзен «күләм» сүзенә алмаштырырга;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүнең билгеләнгән сыйфат күрсәткечләреннән рөхсәт ителгән (мөмкин) тайпылышлар» графасының исемендә «дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты» сүзләрен «эш күләме» сүзләренә алмаштырырга;

искәрмәдә:

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«<8> Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә тутырыла.»;

11 пунктта беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян иәргә:

«Башка күрсәткечләр арасында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә дәүләт йөкләмәсен үтәүдән рөхсәт ителгән (мөмкин булган) тайпылышлар күрсәтелергә мөмкин, аның чикләрендә ул үтәлгән дип санала.».

2. Бу карарның 1 пунктындагы сигезенче – унберенче абзацлары гамәле 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин